| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2021 г.Зеленодольск № 44

2020 елның 29 декабрендәге 24 номерлы Зеленодольск шәһәре Советыны карары белән расланган Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, тоту һәм саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, 2021 елның 22 мартындагы №131ж-2020/2021 Зеленодольск шәһәр прокуратурасы хатына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. 2020 елның 29 декабрендәге 24 номерлы Зеленодольск шәһәре Советыны карары белән расланган Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, тоту һәм саклау кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

««Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон»;

1.2. 13 бүлектә 13.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычның, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, булмавы турында белешмәләр.»;

1.3. 13 бүлектә 13.19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан инвалидларга һәм инвалидлар составында булган гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрендә җитештерелә торган яшел утыртмаларны кисү (сүтү).»;

1.4. 14 бүлекнең 14.1 пунктындагы беренче абзацында «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты рөхсәте булганда» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычның булмавы турында белешмәләрне, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш» өстәргә.

2. Зеленодольск шәһәре Советының 2020 елның 29 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләренә кертелүче яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерүне үткәрү методикасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 4 бүлекнең 4.3 пунктындагы 4.3.3 пунктчасыннан соң «яшелләндерү объекты» сүзләреннән соң «Яшел утыртмалар үз белдегең белән киселгән очракта зыян 5 тапкыр күләмдә исәпләнә. Юкка чыгарылган яки зыян күргән утыртмаларның бәясе методика нигезендә исәпләнә.» җөмләсен өстәргә.

2.2. 4 бүлекнең 4.4 пунктындагы 4.4.2 пунктчасының бишенче абзацында «(1 нче таблица нигезендә билгеләнә)» сүзләреннән соң «j - агач токымнары үз кыйммәте буенча төркемнәр: ылыслы агачлар һәм куаклар өчен-7, 1 нче һәм 2 нче төркемдәге яфраклы агачлар һәм куаклар өчен-5, 3 нче төркемдәге агач һәм куаклар өчен -2.» сүзләрен өстәргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны, шушы карарга кушымта белән, интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**